**1 номерлы КАРАР**
**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлегенең Олы Мәтәскә торак пунктының гражданнар җыены буенча**

**2019 елның 30 ноябре Олы Мәтәскә авылы**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Олы Мәтәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,2019 елның 30 ноябрендә Олы Мәтәскә торак пунктында узган гражданнар җыенының тавыш бирү нәтиҗәләре белән хисап комиссиясе беркетмәсе төзелде, «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлегенең Олы Мәтәскә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

- урам яктырткычлары, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, эш өчен түләү;
- Татарстан, Уткавал урамнары буенча юлларны грейдлау, урамнарны кардан чистарту, вак таш җәю ( таш алу, таш җәю,килешү буенча эш өчен түләү);
- янгын гидранты өчен колонка сатып алу һәм урнаштыру;
-су белән тәэмин итү системасын ремонтлау (су башнясын урнаштыру, су башнясын коймалау өчен төзелеш материаллары сатып алу һәм килешү буенча эшләр өчен түләү);
- «Сабантуй» урынын төзекләндерү (хезмәт күрсәтү пункты, Сабантуй комиссиясе, үзешчән сәнгатьтә катнашучылар өчен җиһазлар, эскәмияләр урнаштыру, буяу өчен материал сатып алу һәм килешү буенча эшләр өчен түләү);

« РИЗА» «КАРШЫ»?».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә:

Җыенда катнашучыларның сайлау хокукына ия булучылары исемлегенә 371 кеше кертелгән;

җыенда катнашучыларның тавыш бирүчеләре саны 188 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәгеләр билгеләнде:

гражданнар җыенында катнашучы 188 кеше «Риза» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлегенең Олы Мәтәскә торак пунктында гражданнар җыены булып узды, гражданнар җыены нәтиҗәләре-дөрес.

2.Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлегенең Олы Мәтәскә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

- урам яктырткычлары, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, эш өчен түләү;

- Татарстан, Уткавал урамнары буенча юлларны грейдлау, урамнарны кардан чистарту, вак таш җәю ( таш алу, таш җәю,килешү буенча эш өчен түләү);

- янгын гидранты өчен колонка сатып алу һәм урнаштыру;

-су белән тәэмин итү системасын ремонтлау (су башнясын урнаштыру, су башнясын коймалау өчен төзелеш материаллары сатып алу һәм килешү буенча эшләр өчен түләү);

- «Сабантуй» урынын төзекләндерү (хезмәт күрсәтү пункты, Сабантуй комиссиясе, үзешчән сәнгатьтә катнашучылар өчен җиһазлар, эскәмияләр урнаштыру, буяу өчен материал сатып алу һәм килешү буенча эшләр өчен түләү);- кабул ителгән.

3. Җыен нәтиҗәләре турында әлеге карарны, гамәлдәге законнар нигезендә, шул исәптән, мәгълүмат стендларында һәм Интернет челтәрендә Олы Мәтәскә авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Мәтәскә авыл җирлеге Башлыгы: М. А. Вәлиуллин